**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Әтнә авыл җирлеге Советы**

**Карар № 115**

**“26“ май 2025 ел** **Олы Әтнә авылы**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Әтнә авыл җирлеге Советының 2013 елның 20 июлендәге 65 номерлы «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә иҗтимагый тәртипне саклау буенча ирекле халык дружиналары турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасының 16.01.2015 ел, №4-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 31.01.2025 ел, №02-08-02-2025/Прдп49-25 номерлы протесты буенча, Әтнә авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Әтнә авыл җирлеге Советының 2013 елның 20 июлендәге 65 нче номерлы «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә иҗтимагый тәртипне саклау буенча ирекле халык дружиналары турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның кереш өлешендәге «2005 елның 1 ноябрендәге 107-ЗРТ номерлы "Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашуы турында"гы» сүзләрен «2015 елның 16 ноябрендәге 4-ЗРТ номерлы "Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында"гы» сүзләренә алыштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 2 маддәсендәге «Татарстан Республикасының 2005 елның 1 ноябрендәге N 107-ТРЗ "Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә катнашуы турында"гы Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «Татарстан Республикасының 16.01.2015 №4-ТРЗ "Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында"гы Татарстан Республикасы Законы» сүзләренә алыштырырга;

1.3. Нигезләмәнең 10 статьясының 2 пунктында «Россия Эчке эшләр министрлыгының «Биектау районы» муниципаль районы буенча «Әтнә»гә хезмәт күрсәтүче полиция бүлегенә» дигән сүзләрне «Россия Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге» дигән сүзләргә алыштырырга;

1.4. Нигезләмәнең 13 маддәсенең 2 пунктының 2, 3 пунктчаларында «Россия Эчке эшләр министрлыгының «Биектау районы» муниципаль районының «Әтнә»гә хезмәт күрсәтүче полиция бүлеге» сүзләрен «Россия Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге» сүзләренә алыштырырга;

1.5. Нигезләмәнең 14 маддәсенең 4 пунктында «ПБ» сүзләрен «Россия Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге» сүзләренә алыштырырга;

1.6. Нигезләмәнең 18 маддәсенең 4 пунктында «Россия Эчке эшләр министрлыгының «Биектау районы»ның «ПБ («Әтнә»)» сүзләрен «Россия Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге» сүзләренә алыштырырга;

1.7. Нигезләмәнең 23 маддәсенең 1 пунктында «Россия Эчке эшләр министрлыгының «Биектау районы»ның полиция бүлеге («Әтнә»)» сүзләрен «Россия Эчке эшләр министрлыгының Әтнә районы буенча бүлеге» сүзләренә алыштырырга;

1.8. Нигезләмәнең 23 маддәсенең 5 пунктында «Татарстан Республикасы территориясендә халыкның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» сүзләрен «Татарстан Республикасында гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында интернет челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Әтнә авыл җирлеге башлыгы
урынбасары:

Совет Большеатнинского сельского поселения — Олы Әтнә авыл җирлеге Советы — ИНН 1610000571

Маликова Р.Р.